**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2020 елның «14» декабреннән № 330

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф системасының иң яхшы педагогик хезмәткәрләрен акчалата бүләкләүгә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының еллык грантын билгеләү турындагы Нигезләмәне раслау хакында»**

Иҗади активлыкны үстерү, белем бирү өлкәсендәге казанышларның сыйфатын арттыру һәм педагогик хезмәткәрләрне югары нәтиҗәләргә ирешү өчен кызыксындыру максатларында, карар **бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф системасы учреждениеләренең иң яхшы педагогик хезмәткәрләрен акчалата бүләкләүгә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының еллык грантын биилгеләү турында Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф системасының иң яхшы педагогик хезмәткәрләрен акчалата бүләкләү өчен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының еллык грантын бирү буенча конкурс комиссиясе составын расларга (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати - телекоммуникацион челтәренең "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы"нда "htt://pravo.tatarstan.ru" һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар 2020 елның 1 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты**
**Җитәкчесе** **Р.Р. Фәсахов**

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның «14» декабре № 330
карарына

Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф системасының иң яхшы педагогик хезмәткәрләрен акчалата бүләкләүгә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының еллык грантын билгеләү турында
Нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының Гранты (алга таба - Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы гранты) - Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы тарафыннан гамәлгә куелган һәм иҗади активлыкны үстерү, белем бирү өлкәсендәге казанышларның сыйфатын күтәрү һәм педагогик хезмәткәрләрнең югары нәтиҗәләргә ирешүенә стимул бирү максатыннан, иң яхшы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре педагогларына район бюджетыннан бүленеп бирелә.

1.2. Ел саен 10 мең сумга кадәр 10 грант бирелә.

1.3. Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы гранты районның мәгариф системасы учреждениеләренең иң яхшы педагогик хезмәткәрләренә югары педагогик осталык һәм район мәгарифенә шактый зур өлеш кертүчеләргә өчен бирелә.

1.4. Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы гранты район мәгариф системасы учреждениеләренең сайлап алу конкурсы аша үткән иң яхшы педагогик хезмәткәрләренә бирелә.

1.5. Педагог грантны 5 ел узганнан соң гына яңадан алырга хокуклы.

## 2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы грантын бирүнең төп принциплары.

2.1. Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы грантын бирүнең төп принциплары булып түбәндәгеләр тора:

- Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы грантын алуга конкурста катнашучыларның хокуклары тигезлеге;

- Яңа Чишмә районы Башлыгы грантын алу белән бәйле мәгълүматның һәркем өчен ачык булуы;

- ярышлылык (конкурс нигезе).

3. Иң яхшы педагогик хезмәткәрләрне конкурс нигезендә сайлап алу критерийлары.

3.1. Яңа Чишмә районы Башлыгы гранты конкурс нигезендә бирелә.

3.2. Конкурста катнашу өчен документлар гариза бирүче тарафыннан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенең оештыру төркеменә, исемлек нигезендә тапшырыла.

3.3. Претендентларны конкурс нигезендә сайлап алу ике төркем критерийлар нигезендә башкарыла:

- квалификация сайлап алуын үткәрү (алга таба - катнашу критерийлары)

конкурс буенча сайлап алу (алга таба-сайлап алу критерийлары)

3.4. Катнашу критерийлары:

- педагог урта махсус яки югары һөнәри белемгә ия;

- педагог беренче яки югары квалификация категориясенә ия;

- төп эш урыны - Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф системасында белем бирү учреждениесе яки оешма;

- белгечлек буенча педагогик эш стажы кимендә 3 ел.

Сайлап алу критерийлары:

1. Соңгы 3 елда укучыларның уку казанышларының уңай динамикасы:

- укучыларның белем сыйфаты район күрсәткечләреннән югарырак,

- БДИ нәтиҗәләре район күрсәткечләреннән югарырак,

- олимпиадаларда, конкурсларда, ярышларда (район, республика, бөтенроссия, халыкара дәрәҗәдәге һ.б.) 1 һәм аннан да күбрәк призлы урыннар булу.

2. Сыйныф җитәкчесе сыйфатында эшчәнлекнең уңай нәтиҗәләре:

- тәрбияләнүчеләренең республика конкурсларында 1 һәм аннан да күбрәк призлы урыннары булу һәм һөнәри осталык бәйгеләрендә шәхси нәтиҗәләр.

- фән һәм тәрбия эшендә, методик эштә заманча белем бирү технологияләрен куллану, белем бирү технологияләрен һәм системаларын кертү буенча республика, район мәйданчыкларында катнашу, эксперименталь - тәҗрибә эшендә катнашу;

- үз педагогик тәҗрибәңне муниципаль, республика һәм бөтенроссия дәрәҗәсендә тарату (ачык дәресләр, чыгышлар, мастер – класслар, Интернет – конференцияләрдә катнашу һ. б.), матбугатта методик эшләнмәләр чыгару;

- муниципаль, республика һәм Бөтенроссия һөнәри конкурсларда нәтиҗәле катнашу яки катнашуга әзерләү.

3.5. Катнашу критерийлары буенча конкурс комиссиясенә дәгъва кылучы өчен тапшырыла торган документлар исемлеге:

- урта махсус һәм югары һөнәри белем турында диплом күчермәсе;

- Дәгъвачының хезмәт кенәгәсенең күчермәсе;

- гариза бирүчене тәкъдим итү;

- аттестация кәгазе.

3.6. Конкурста теләсә кайсы фән өлкәсенең педагогик хезмәткәрләре катнаша ала.

4. Иң яхшы педагогик хезмәткәрләрне конкурс нигезендә сайлап алу тәртибе.

4.1. Конкурс комиссиясенә гаризалар 1 июньнән 30 июньгә кадәр кабул ителә.

4.2. Конкурс сайлап алуы катнашу критерийлары һәм сайлап алу критерийлары нигезендә гамәлгә ашырыла һәм 1 августка кадәр уздырыла.

5. Конкурс комиссиясе.

5.1. Район Башлыгы грантына Конкурс ел саен үткәрелә.

5.2. Конкурсны конкурс комиссиясе – коллегиаль орган оештыра, аның саны һәм персональ составы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

5.3. Комиссия составына Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесе, мәгариф учреждениеләре һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләре керә.

5.4. Комиссия рәисе - Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары.

5.5. Конкурс комиссиясе эшчәнлеге иреклелек, тигез хокуклылык, законлылык принципларына нигезләнә.

## 6. Конкурс комиссиясе компетенцияләре.

6.1. Конкурс комиссиясе:

- конкурс үткәрүнең конкрет шартларын, тәртибен һәм ысулларын билгели;

- конкурс турында мәгълүмати хәбәр текстын раслый;

- массакүләм мәгълүмат чараларында конкурс турында мәгълүмат бастыруны тәэмин итә;

- конкурста катнашу өчен гаризалар кабул итү һәм теркәүне гамәлгә ашыра. Гаризаларны квалификация буенча сайлап алуны үткәрә;

- конкурста катнашу өчен гаризалар исемлеген төзи;

- дәгъвачының катнашу критерийлары буенча документлар пакетына техник экспертиза үткәрә;

- конкурс үткәрә: претендентның эшчәнлегенә бәя бирә, конкурста җиңүчеләрне билгели;

- үткәрелгән бәяләү нәтиҗәләре нигезендә претендентлар рейтингын төзи. Үткәрелгән бәяләү нәтиҗәләре буенча сайлап алынган претендентлар саны билгеләнгән квотадан күбрәк булса, дәгъва итүчеләрнең бер үк санда балл җыйган документларына өстәмә бәя бирелә.

- конкурс нәтиҗәләре турында беркетмәгә кул куя, конкурста катнашучыларга аның нәтиҗәләре турында хәбәр итә;

- массакүләм мәгълүмат чараларында конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмати хәбәр бастыруны тәэмин итә;

- конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе конкурста җиңүчеләр һәм һәр заявканы карау нәтиҗәләре турында карар кабул итә. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгына беркетмәне тапшырганнан соң, конкурс комиссиясе эшчәнлеге тәмам дип санала;

- конкурста җиңүчеләр Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнәләр.

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның «14» декабре № 330
карарына

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф системасының иң яхшы педагогик хезмәткәрләрен акчалата бүләкләүгә еллык грантын бирү буенча конкурс комиссиясе составы

Комиссия рәисе:

| | | |
|---|---|---|
| Еронтьев Александр Леонидович | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |

Комиссия рәисе урынбасары:

| | | |
|---|---|---|
| Улитин Александр Борисович | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге начальнигы урынбасары |

Комиссия секретаре:

| | | |
|---|---|---|
| Төхфәтуллина Лилия Рафик кызы | - | "Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль учреждениесенең педагогик кадрларын аттестацияләү һәм уку дисциплиналары буенча методисты |

Комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Валасеев Владимир Григорьевич | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы мәктәп директорлары Советы рәисе (килешү буенча) |
| Ермолаева Ирина Николаевна | - | «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә гимназиясе" муниципаль бюджет белем бирү учреждениясе директоры урынбасары |

| | | |
|---|---|---|
| Нурхаметова Ләйсән Рифхат кызы | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф оешмаларының профсоюз оешмалары Советы Рәисе (килешү буенча) |
| Сираева Гөлфия Ләбиб кызы | - | «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль учреждениясенең структур бүлекчәсе җитәкчесе - мәгариф бүлеге начальнигының (укыту-методик эш буенча) урынбасары |